Казан
(Идел буе)
федераль
университеты
газетасы

# DARELFØNYN
УНИВЕРСИТЕТ

12+

№2
(95)

30 гыйнвар
2014 ел



# Җаваплылыкның яңа баскычы

Студентлар көне бәйрәм ияләре өчен бүләкләргә, матур тәбрикләү сүзләренә бай булды. 25 гыйнвар көнне Татарстан Республикасының «Ел студенты» премиясен тапшыру тантанасында уку йортыбызга тиңнәр булмады дияргә мөмкин. КФУ студентлары, күп кенә номинацияләрдә җиңү яулап, махсус бүләкләргә ия булып, белем йортыбызга тагын бер зур дәрәҗәле исем алу мөмкинлеге бирде. Казан федераль университеты «Ел вузы» булды. Бу – безнең зур, уртак җиңү! Уку йортыбызның шундый уңышларга ирешүендә һәр укытучының, хезмәткәрнең, студентларның, җитәкчелекнең өлеше зур.
Алга таба да бергә-бергә зур үрләр яуларга язсын!

*Дәвамы 2 биттә*

## Вакыйгалар эзеннән

КФУның Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм көнчыгышны өйрәнү институты студенты **В.ВДОВИН** 24 гыйнвар көнне М.В.Ломоносов ис. Мәскәү дәүләт университетында узган фарсы теле буенча **X БӨТЕНРОССИЯ ОЛИМПИАДАСЫНДА I УРЫННЫ ЯУЛАДЫ**.

• • • •

**25 ГЫЙНВАР – БАРЛЫК СТУДЕНТЛАР КӨНЕН КФУ СТУДЕНТЛАРЫ «УНИКС»ТА БИЛГЕЛӘП ҮТТЕЛӘР**. Быел бәйрәмгә яшьтәшләрен котларга Төньяк Кавказ, Ульяновск һәм Тула студентлары да килгән иде. Тантананы ректор И.Гафуров ачып җибәрде. Ул студентларны бәйрәм белән котлады һәм Универсиаданы уздыруда ярдәм күрсәткән волонтерларга аерым рәхмәтен җиткерде. Концертта студентлар җыр-биюләрен, театраль сәхнә, ШТК чыгышларын тәкъдим иттеләр.

• • • •

**25 ГЫЙНВАР** көнне Н.П.Огарев ис. Мордовия дәүләт университетында **XI ТӨБӘКАРА«ИДЕЛ БУЕ ТАТЬЯНАСЫ» КОНКУРСЫ БУЛЫП УЗДЫ**. Анда республикабыз данын Яр Чаллы институтының 1 курс студенты Татьяна Гусева яклады. Нәтиҗәдә ул «Интернет-тавыш бирү» номинациясендә җиңүгә иреште. Таняны шулай ук «Мисс күркәмлек» номинациясе буенча да бүләкләделәр. Җиңүчене котлыйбыз!

• • • •

**25 ГЫЙНВАРДА** ТРның Махсус дәүләт стипендиясенә лаек булган **СТУДЕНТЛАРНЫ** һәм **АСПИРАНТЛАРНЫ БҮЛӘКЛӘҮ ТАНТАНАСЫ УЗДЫ**. Быел аны Татарстанның 80 студенты һәм аспиранты алачак. Шуларның 20се Казан федераль университетында укый.

• • • •

**КФУ**ның чираттагы **РЕКТОРАТ УТЫРЫШЫ 27 ГЫЙНВАР** көнне **БУЛДЫ**. Көн тәртибендә барлыгы 5 мәсьәлә каралды. Административ эшчәнлек буенча проректор – аппарат җитәкчесе **А.ХАШОВ** контроль боерыкларның үтәлеше һәм 27 гыйнвар-3 февраль аралыгында КФУда узачак чаралар планы белән таныштырды. Кабул итү комиссиясенең җаваплы сәркатибе **С.ИОНЕНКО** 2014/2015 уку елында абитуриентларны кабул итүгә әзерлек дәрәҗәсе хакында сөйләде. Ул һөнәри ориентация эшчәнлегенең төп юнәлешләре, булачак абитуриентлар белән эшләгәндә мәгълүмати белем бирү технологияләрен куллану, КФУның «Мәгариф. Карьера» бөтенроссия күргәзмәсендә катнашуы турында җиткерде. Белем бирү ресурслары үсеше департаменты директоры **ГАЛИНА ИВШИНА** КФУда 2013 елда электрон белем бирү буенча нәтиҗәләр ясады. Ул белем бирүдә электрон курсларны куллану дәрәҗәсен саннар ярдәмендә күрсәтте.

Ректоратта «Экспериментал астрофизика» кафедрасы булдыруны яклап тавыш бирелде. Кафедра Физика институтының астрофизика һәм космик геодезия бүлеге структурасында КФУ һәм РФ Фәннәр академиясенең махсус астрофизика обсерваториясе белән хезмәттәшлек турындагы килешү кысаларында оештырыла.

Утырыш тантаналы рәвештә тәмамланды. Ректор **И.ГАФУРОВ** Татарстан Республикасының «Ел студенты» исеменә лаек булган КФУның Икътисад һәм финанслар институты студенты **И.ХӨҖҖӘТОВНЫ** җиңүе белән тәбрикләде һәм аңа iPad алу өчен сертификат тапшырды.

• • • •

**27 ГЫЙНВАРДА КФУ**га РФ Президентының Идел буе федераль округы Вәкаләтле вәкиле аппаратының дәүләт хезмәте, кадрлар һәм дәүләт бүләкләре мәсьәләләре буенча департамент башлыгы **Н.АНТОШИНА КИЛДЕ**. Визит кысаларында ул ректор **И.ГАФУРОВ** һәм Казан университетының **ДӘҮЛӘТ** һәм **МУНИЦИПАЛЬ ИДАРӘ ЮГАРЫ МӘКТӘБЕ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕ БЕЛӘН ОЧРАШТЫ**. Очрашу барышында КФУның Дәүләт һәм муниципаль идарә Югары мәктәбе белән департамент арасындагы хезмәттәшлек мәсьәләсе каралды.

• • • •

Шул ук көнне Яшьләр эшләре буенча федераль агентлык җитәкчесе **С.БЕЛОКОНОВ**, Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт җитәкчесе **С.КРАВЦОВ РОССИЯНЕҢ СТУДЕНТЛАР АКТИВЫ БЕЛӘН ОЧРАШУ ҮТКӘРДЕ**. Очрашуда КФУ активистлары да катнашты. Чарада Бөтенроссия яшьләр проектлары җиңүчеләрен бүләкләү тантанасы булды. Алар арасында КФУ студентлары Г.Җәләев, Э.Маркарьян, Е.Панкова бар иде. Җиңүчеләрне тәбриклибез!

*Мәгълүмат КФУ матбугат үзәгеннән алынды*

**• Уртак җиңү**

# Җаваплылыкның яңа баскычы

Әңгәмәдәш **Ләйсән ИСХАКОВА**

**–Илдар, җиңүең белән сине! 2013 ел ахырында гына син КФУның «Ел студенты» конкурсы гран-при иясе булган идең. Бүген исә республикабызның «Ел студенты» исемен йөртәсең. Бу уңайдан нинди хисләр кичерәсең?**

-Татарстан Республикасының «Ел студенты» бәйгесенең җиңүчесе булу - минем өчен зур дәрәҗә. Бер үк вакытта бу - җаваплылыкның яңа бер баскычы. Күңелдә хисләр, кичерешләр ташкыны... Ник дигәндә, мин үз алдыма ярты ел элек куйган максатларымның берсенә ирештем. Бүләкләү тантанасы узган залдагы атмосфера – студентлык рухы – мине аеруча тәэсирләндерде. Әлбәттә, ел саен уздырыла торган ТРның «Ел студенты» студентлар премиясе тапшыру - бүләкләү тантанасы гына түгел, ә республикабызның барлык студентлары өчен дә зур бәйрәм ул.

**- Җиңүгә таба юл бормалы булдымы?**

- Беренче курстан бирле студентлар арасында актив рәвештә җәмәгать эшләре белән шөгыльләнү дәверендә күпне күрергә туры килде: җиңүләр һәм җиңелүләр, очышлар һәм егылулар. Әмма туганнарым, якыннарым, дусларым һәм командамның ярдәме үзгәрешсез калды.

**- «Ел студенты» исеменә лаек булучының җиңүләре күп була. Ә менә сине бигрәк тә кайсы бәйгеләр мондый уңышка китерде?**

- Чыннан да, җиңүләр аз булмады. Университетта уку дәверендә спорт,



күңел ачу чаралары, фәнни эшчәнлек белән бәйле чараларда катнаштым, аларны оештыру белән шөгыльләндем. «Вверх!» республика конкурсында, «Кадрлар резервы» республика проектында, «КФУның студентлар лидеры – 2012» бәйгесендә призер, «Студентлар лидеры – 2013» республика проектында финалист, «КФУның Ел студенты - 2013» студентлар премиясендә «Гран-при» номинациясендә җиңүче булуымны үземнең иң зур уңышларым дип саныйм.

**- «Ел студенты» исемен яулар өчен, студент нинди сыйфатларга ия булырга тиеш?**

- «Ел студенты», барлык башка лидер һәм җитәкче кебек үк, кыю, үз көченә ышанучан, үз өстенә җаваплылык алудан курыкмый торган, креатив кеше булырга тиеш. Һәм тагын бер мөһим сыйфат: команда составында эшли белү сәләте.

**- Җиңүче буларак, син дөньяның теләсә кайсы югары уку йортына укырга керә аласың. Бу мөмкинлектән файдаланырга уйлыйсыңмы?**

- Әлбәттә! Чит ил югары уку йортында белем алу мөмкинлеге һәркемгә бирелми. Әмма бүген минем өчен университетны тәмамлау мөһимрәк. Әлегә кайсы югары уку йортына укырга керәчәгемне уйламадым. Тик белем юнәлеше хәзерге белгечлегем – финанслар һәм кредит белән бәйле булачагын тәгаен әйтә алам.

**- Киләчәккә планнарың нинди?**

- Әйткәнемчә, бүген минем төп максат – Казан федераль университетын тәмамлап, кулга диплом алу. Тагын бер максатым «ТР Студентлар лигасы» оешмасының якын киләчәгә белән бәйле.

**- Студентларга нинди теләкләрең бар?**

- Сессияне тапшырганда - уңышлар, белем үрләренә менгәндә - сабырлык, үҗәтлек һәм тырышлык, карьерада - ышанычларның аклануын, тормышта - куаныч һәм бәхет, иҗади тормышта истә калырлык вакыйгаларның, яңа ачышларның күбрәк булуын телим! Без, студентлар, барысын да булдырабыз. Нибары теләк кирәк!

**- Әңгәмәң һәм матур теләкләрең өчен рәхмәт, Илдар!**

***Марсель Бадыкшин, Руслан Давлетшин фотолары***



■ ТР Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин КФУ ректоры И.Гафуровка төп бүләкне тапшыра



■ «Ел журналисты» номинациясендә җиңүче – ГКҺСФИ студенты Л.Закиров «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе генераль директоры И.Әминов белән



■ «Чит ил студенты» номинациясендә махсус бүләккә лаек булган Рөстәм Мусин

**• Халыкара мәйдан**

# Дөньядагы урыныбыз да түрдә!

**Дания ФАТЫЙХОВА**

24 гыйнвар көнне Казан федераль университетында яңа бүлекчә – Халыкара фәнни совет үз эшчәнлеген башлап җибәрде. Бу көнне аның беренче утырышы булды.

Мондый советларның барлыкка килүе Россия университетлары өчен әле яңа күренеш һәм бу эшчәнлеккә беренче адымны КФУ ясады. Ректор **И.Гафуров** сүзләренчә, Совет вузның приоритетлы фәнни юнәлешләрен үстерүне координацияләү, дөньякүләм фәнни һәм белем бирү берләшмәләрендә Казан университетының позицияләрен ныгыту максатыннан оешты.

Халыкара фәнни совет составына дөньякүләм танылган 13 бөек галим керә. Беренче утырышта химия буенча Нобель премиясе лауреаты, РИКЕН президенты Рёдзи Ноёри (Японидән Skype элемтәсе аша), Страсбург университеты профессорлары Марат Йосыпов һәм Александр Варнек, Икътисад югары мәктәбе Белем бирү институтының фәнни җитәкчесе Исак Фрумин, Көньяк Париж университеты профессоры Анри Рафаэль Аллул, Инсбрук университеты профессоры Рудольф Гримм, Геология фәннәре буенча халыкара союз президенты, Потсдам университеты профессоры Роланд Оберхенсли, Бирмингем университеты профессоры Джон Раундлар катнашты.



Влад Михневский фотосы

Ректор И.Гафуров җитәкчелегендә КФУ администрациясе кунакларны университет, аның эшчәнлеге, алдагы планнар, куйган максатлар белән таныштырды. Советның икенче өлешендә тәкъдир ителгән презентацияләр турында фикер алыштылар. Икенче көнне Халыкара фәнни советта алга таба алып барылачак эшчәнлек хакында сөйләштеләр. Чарада катнашучылар үзләренең алган тәэсирләре һәм барлыкка килгән тәкъдимнәре белән уртаклаштылар. Ике көнлек җыелышның нәтиҗәсе итеп, бирегә яңгыраган барлык теләк-тәкъдимнәр кертелгән протокол төзеләчәк.

Университетыбызга шундый зур дәрәҗәле, мөхтәрәм кешеләрнең килеп, бездән үзләре өчен яңа идеяләр алуы, тәҗрибә уртаклашуы – Казан федераль университетының фән дөньясында үзенең ныклы урыны булу турында сөйли.

* * *

Шул ук көннәрдә университетыбызга Африка илләреннән җитәкчеләр, вәкаләтлекнең әйдәп баручы хезмәткәрләреннән торган делегация килде. Африкадан шундый зур кунаклар килү – университет тарихында беренче тапкыр, шуңа күрә безнең өчен бу бик зур вакыйга.

Делегация составында Бенин, Конго, Маврикий, Руанда, Чад, Гвинея-Бисау, Замбия, Кот-д'Ивуар, Эфиопия, Тунис, Мали, Сьерра-Леоне кебек республикаларның Россия Федерациясендәге гадәттән тыш һәм тулы вәкаләтле вәкилләре һәм Мозамбик, Бурунди, Танзания, КАР, Зимбабве, Джибути вәкаләтлекләренең вәкилләре бар иде. Кунакларның килү максаты – Казан федераль университеты белән партнерлык элемтәләрен ныгыту.

Бүгенге көндә КФУда илледән артык африкалы белем ала. Бу күрсәткеч югары түгел һәм аны арттыру өстендә эшләргә кирәк дигән нәтиҗәгә килделәр. Әлеге фикерне И.Гафуров та хуплады. Алай гына да түгел, ул Африка уку йортларында университетыбызның белем бирү үзәкләрен булдыру идеясен тәкъдим итте. Ректор фикеренчә, бу безнең студентларыбызга стажировка үтү өчен менә дигән мәйдан булачак! Бу идея кунаклар күңеленә бик хуш килде. КФУда ике Африка теле – суахили һәм африкаас – телләрен укытуны кертергә җыенганны белгәч, алар үз ягыннан тел белүче укытучылар һәм кирәкле уку әсбәплары белән ярдәм итәргә сүз бирде.

Чара барышында университетыбызда чит ил студентларын укытуның нечкәлекләре турында сөйләштеләр һәм уртак фәнни-белем бирү эшчәнлеге турында фикер алыштылар. Алга таба университет җитәкчелеге белән ике яклы очрашулар булдырырга кирәк дигән нәтиҗә ясалды. Бу исә кунаклар КФУ белән хезмәттәшлеккә бик җитди карыйлар дигән сүз!





Влад Михневский фотолары

• Галимнәребез

# Тарихчы-галим-педагог-гражданин!

**Олег СИНИЦЫН,** тарихи белем бирү кафедрасы мөдире, профессор

Россиянең атаклы тарихчысы Василий Осипович Ключевский: «Һәр галимнең һәм язучының тормышында иң мөһим биографик факт – ул китаплар, иң мөһим вакыйгалар – фикерләр», – дип язып калдырган. Бу юллар тулысы белән Булат Фәйзрахманович Солтанбековның фәнни-педагогик һәм сәяси-иҗтимагый эшчәнлегенең асылын ачып бирә. Күптән түгел генә галим үзенең тормыш һәм иҗат биографиясенең тагын бер түгәрәк датасын – 85 яшьлек юбилеен билгеләде.



Казанда һәм Татарстанда Б.Ф.Солтанбековны күпләр: Казан педагогика институтындагы хезмәттәшләре, Казан дәүләт университеты, Казан консерваториясе, Мәгариф үсеше институты тарихчылары һәм галимнәре ҮЗЕБЕЗНЕКЕ дип саныйлар! Бу күктән алып әйткән сүзләр түгел, чөнки әлеге үзенчәлекле шәхес, булдыклы оештыручы, талантлы галим-тикшерүче Казан, Татарстан, Россиянең фәнни-мәгариф һәм иҗтимагый тормышына зур өлеш керткән һәм әле дә бу эшчәнлеген бик актив алып бара.

Булат Солтанбековны Казан дәүләт педагогика институты белән бик күп җепләр бәйләп тора. Биредә ул, тарих-филология факультетын тәмамлап, югары белемгә ия була. 1947 елдан Шәмәрдән урта мәктәбендә тарих укытучысы булып эшли башлый. 1961-1981 елларда КДПИда доцент, проректор, партком сәркатибе вазифаларын башкара. Б.Ф.Солтанбеков республикабызның мәгариф системасын үстерүгә күп көч һәм энергиясен сарыф итә. 1954-1961 елларда ул КПССның Татарстан обкомының мәктәп һәм фән бүлегендәэшли, 1990 елларда Мәгариф хезмәткәрләренең квалификацияләрен күтәрү институтында кафедра җитәкли, урта мәктәпләр өчен Татарстан тарихы дәреслекләрен яза. Алар арасында укучылар яратып өлгергән дәреслек– Ватан тарихының иң катлаулы саналган дәвере – 1917-1995 еллар тарихы китабы дә бар. Булат Солтанбеков – 1917 елның февраленнән алып, 1941 елга кадәр булган беренче дүрт бүлек авторы. Дәреслекләрдә күп санлы тарихи документлар урын алган. Укучыларга бербersенә каршы килә, торган материалларны аңлау һәм аларга төшенү, берьяклы бәяләмәләрдән качу өчен, һәр бүлек ахырында сораулар һәм биремнәр ярдәмгә килә.

Б.Солтанбековны шулай ук Татарстандагы сәяси репрессияләр тарихы буенча монографияләр авторы, яхшы публицист, күп санлы газета-журналлар редколлегияләре әгъзасы, «Эхо веков» журналын ачу инициативасын белдергән шәхес буларак та хөрмәт итәләр.

Олы галимнең педагогик эшчәнлегенә дә аерым басым ясыйсым килә. Кайда гына хезмәт куймасын – Казан педагогика институтымы ул, Казан дәүләт университетымы, Мәдәният институты яисә консерваториями – ул бөтен җирдә студентларында гражданлык сыйфатларын тәрбияләүгә йөз тотып эшли.

Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, ТРның атказанган мәдәният эшлеклесе, Россиянең мактаулы архивисты Б.Ф.Солтанбеков хәзер дә иҗади, фәнни эшчәнлеген актив рәвештә дәвам итә. Күптән түгел ул легендар шәхес – С.Д.Игнатьевка багышланган «Свет и тени биографии министра госбезопасности» китабын бастырып чыгарды. «У истории нет лишних страниц» исемле тагын бер яңа очерклар китабы басмага тапшырылган. Анда Николай Пи, аның язмышы, гаиләсе турында әле беркайда да дөнья күрмәгән документлар урын алган.

Булат Солтанбековны күркәм юбилее белән тәбрик итәбез. Аңа озын һәм бәхетле гомер, яңа иҗади үрләр телибез!

• Чара

# Алдыбызда зур максатлар

**Ләйсән ИСХАКОВА,** Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

29 гыйнвар көнне Кайгыртучанлык советы утырышлары залында КФУ ректоры, институт директорлары катнашында «Мәгълүмати-коммуникацион һәм космик технологияләр» дип исемләнгән дисциплинаара семинар булып узды. Семинар бу приоритетлы юнәлеш буенча юл картасын тәкъдир итү чарасы да булды.

Университетыбызда мәгълүмати-коммуникацион һәм космик технологияләр өлкәсендә барлыгы 4 төп юнәлеш буенча эшчәнлек алып бару планы бар. Бу эшчәнлекне КФУда 4 база тормышка ашыра: зур мәгълүматлар тупланмасы, робототехника, интеллектуаль эшчәнлекне автоматлаштыру, визуализацияләү һәм интерфейс. Мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүмати системалар Югары мәктәбе, Н.И.Лобачевский исемендәге математика һәм механика институты, Хисаплау математикасы һәм мәгълүмати технологияләр институты, Физика институты. Бу төп юнәлеш кысаларында әлеге институтлар КФУның башка институтлары белән дә үзара бәйләнештә эшләячәк. Бу хакта Мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүмати системалар Югары мәктәбе директоры **Айрат Хәсьянов** җиткерде. Ул үзенең презентацияле чыгышында әлеге төп юнәлешләрнең асылы турында тулырак сөйләде.



Влад Михневский фотосы

Чыгышын тәмамлаганнан соң, Айрат Хәсьянов хезмәттәшләренә мөрәҗәгать итеп, теләк-тәкъдимнәрен җиткерүләрен үтенде. Шуннан соң очрашу түгәрәк өстәл формасын алды. Катнашучылар юл картасы планының ни рәвешле үтәләчәге хакында сөйләштеләр.

Бүген робототехника өлкәсе – заманча тренд. Әмма, ни кызганыч, Россиядә бу өлкәдә әллә ни зур ачышлар да, тикшеренүләр дә ясалмый. Шуңа да бу юнәлештә күрсәткечләргә ирешү университетыбыз алдына куелган төп максатларның берсе булып тора.

Автоматлаштыру да хәзерге көндә күп өлкәләрдә кулланыла. Көндәлек тормыштагы техник инцидентларның 80% н машина ярдәмендә җайга салып була. Нәтиҗәдә, белгечләргә вакытка экономия ясарга мөмкинлек туа. Бу өлкәдә Н.И.Лобачевский исемендәге Математика һәм механика институтының дифференциаль тигезләмәләр кафедрасында билгеле бер дәрәҗәдә нәтиҗәле эшләр башкарыла инде. Бу хакта институт директоры **В.А.Чугунов** җиткерде. Космик юнәлештәге эшчәнлек тә физика институты белгечләре тарафыннан тормышка ашырылачак.

Визуальләштерү һәм интерфейс өлкәсендәге бүгенге уңышлар фәнни мәгълүматны күзаллауда нәтиҗәле күрсәткечләргә ирешергә ярдәм итә. Институтлар алдында бу юнәлештә дә эшчәнлек алып бару бурычы куелган.

Семинарда КФУ ректоры **Илшат Гафуров** та чыгыш ясады. Ул һәр юнәлешнең планын, аны тормышка ашыруга хезмәт итәчәк белгечләрнең исемлеген тәгаенләп бетерүне сорады. «Сүзләр – сыйфати күрсәткеч», - диде ул бу уңайдан. Ректор беренче этапта юнәлешләр колачын бераз тарайтырга һәм заказ бирүчеләре булган юнәлешләргә өстенлек бирергә тәкъдим итте.

• Йөз ел әлек

# Казан хәбәрләре

**Ленар ГОБӘЙДУЛЛИН** әзерләде

### Губернаторның мөселманнарны зиярат кылуы

3 гыйнварда кичке сәгать алтыда Казанның яңа губернаторы П.М.Боярский (рус җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе, Казанның соңгы губернаторы (1913-1917)) җәнабләре мөселманнар арасына төште. Губернатор иң әүвәл Галимҗан хәзрәт (дин һәм җәмәгать эшлеклесе. Бу вакытта «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе мөдәррисе, Казанда бишенче мәхәллә мәчете имам-хатыйбы) мәсҗелесенә төште. Анда җыелган халык белән падишаһ әгъзәмнең сәламәтлеге өчен догалар кылынды һәм, мөселманнарның үтенүе буенча, губернатор мөселманнарның гарыз сәдакатьләрен [үтенечләрен] бәян иткән телеграмманы падишаһ әгъзәмгә җибәрергә булды. Шуннан соң Боярский җәнабләрен дамелла Галимҗан әл-Баруди хәзрәт үз өенә дәгъвәт итте [чакырды]. Губернатор бу дәгъвәтне кабул итеп, берничә минутка Галимҗан әл-Баруди хәзрәт ханәсенә тәшриф итте [барып килде].

*1914. – №305. – 5 гыйнвар*

### Татар яшьләре кичәсе

Рождественский тәгътыйле [каникулы] вакытында рус мәктәпләрендә укый торган татар яшьләре буш була вә шул бушлыктан истифадә итеп [файдаланып], башка шәһәрләрдән дә Казанга шактый укучы вә укытучы яшьләр җыела. Шул мөнәсәбәт белән һәр елны укучы татар яшьләре бу вакытта хосусый кичә ясый. Бу кичә инде хәзер Казан яшьләренең гадәтенә (традициясенә) кереп китте. Бу кичәне яшьләр көз башыннан көтеп ала.

Менә шул кичәнең бу елгысы өченче кич Шәрык клубы залында ясалды. Кичәне ясаучылар тарафыннан хосусый дәгъвәт белән генә җыелган бу кичәдә татар мөхәррирләре, адвокатлары, курсистка, студентлары һәм башка укучылары хәзер булып, барлыгы туксан кадәр кеше мөшарәкәт итте [катнашты].

Мөшарәкәт итүчеләрнең үз араларыннан бер оркестр һәм татар җырларын җырлар өчен, кызлар вә егетләр катыш хор ясалган иде. Татар музыкасы, татар җырлары, танцалар булды һәм гаилә кичәләрендә уйнала торган уеннар иҗраэ ителде [башкарылды]. Кунакларга чәй, плау һәм фрукталар тәкъдим ителде. Яшьләр бик рухлы сурәттә, күңелле вә матур итеп вакыт үткәрделәр. Кичәне ясашуда бик хезмәт иткән студент Шәйхулла әфәнде Алкинга һәм, акча алмыйча, Шәрык клубының залын биреп торган клуб хәяте идарәсенә рәхмәт әйтмәскә мөмкин түгелдер. Шәрык клубы үзенең шул көнгә тәгаен иткән концертын кичектереп, татар яшьләрен үзендә кунак итте.

Кичә бик рухлы сурәттә төнге 3 сәгатькә кадәр сузылды.

*1914. – №306. – 6 гыйнвар*

### Сәях профессор

Германиядә Потсдам шәһәре дарелфөнүненең [югары уку йорты] (киң кабул ителгән мәгънәдә университет түгел, чөнки Потсдам шәһәрендә университет 1991 елда гына ачыла) профессорларыннан Н.Риссом җәнабләре бу көннәрдә шәһәребезгә тәшриф ителмештер. Профессор җәнабләре татарлар әхвале белән танышырга тели икән. Ак мәсҗедтә дә намаз вакытында хазер булган. Намаздан соң дамелла Галимҗан хәзрәт илә танышып, мәдрәсәи «Мөхәммәдия»не карарга мөсагадә [мөмкинлек] алган. Җомга көн Шәрык клубында театрны тамаша иткән. Кичә газеталар редакцияләрен, матбагаларны һәм китапханәләрне зиярат иткән. Профессор җәнабләре русча белмәдегеннән, танышкан адәмнәре илә немецча, французча һәм инглизчә лисаннарында мөсахәбә [аралашкан] иткән.

*1914. – №311. – 12 гыйнвар*

*Материаллар «Кояш» газетасыннан алынды*

● Әдәби сәйләннәр

Хөрмәтле газета укучыларыбыз! Сезнең игътибарга университетыбыз студентлары иҗат иткән шигырьләрне тәкъдим итәбез.
Яшь иҗатчыларыбызның күңел кылларын тибрәткән хисләре сезгә дә хуш килер дип уйлыйбыз.

## Казан...

**Зөлфия БӘДРЕТДИНОВА**

*Бүген никтер бик тын урамнарда,*
*Әллә инде бер-бер хәл булган?*
*Данлы, матур Казан шәһәрендә*
*Бер минутка тарих тукталган...*

*Борынгыда ниләр булганнарын*
*Бер мизгелдә күргәндәй булам.*
*Күзләремә яшьләр килде хәтта,*
*Үткәннәрдән бүген дә куркам.*

*Бүгенгегә кайттым,*
*Казан шәһәремә,*
*Анда кышлар бүген, күрәсез.*
*Балкып тора шәһәр яктылыктан,*
*Гәрчә үзегез дә беләсез.*

*Тау башында Кол Шәрифем,*
*Яңгырап тора азан тавышы.*
*Болгарлардан килгән тарихларның,*
*Бүгенгедә калган заргышы.*

*Манарада патша каберләре,*
*Элеккегә безне эндәшә.*
*Кремль капкалары дәшми калмый*
*Безнең белән ул да серләшә.*

*Үткәннәрне онытмыйча гына,*
*Янә алга атлап барабыз.*
*Казан тарихына керер өчен,*
*Без дә тирән эзләр салабыз...*

## Бәхетең үзеңнең кулыңда

**Ильмира КАМАЕВА**

*Ялгышсаң, кайгыра, борчыла*
*Эх, рәхәт әнинең куенында,*
*Тик менә, балачак тиз уза...*

*Шәһәрдә син ялгыз... Дуслар да*
*Әверелә кайвакыт дошманга.*
*Киңәшкә бик саран таш кала...*
*Бәхетең үзеңнең кулыңда.*

*Шәһәрнең шаукымы үз хәзер,*
*Түгел мин ялгызым калада.*
*Соң чиккә җитсәң дә, бирешмә,*
*Бәхетең үзеңнең кулыңда!*

*Аллага ялварам таңнарда,*
*Һәр иртә чыгамын юлларга.*
*Бәхетле булырга хаклы бит*
*Һәр инсан бу якты дөньяда.*

*Йөрәктә җылылык калмаса,*
*Күңелем үрелә кояшка.*
*Нурларны үткәрми халыкка*
*Ай, кырыс икән соң таш кала.*

*Тукталыш саныймын һәрвакыт,*
*Кондуктор эндәшә миңа да.*
*Тиеннәр тәгәри идәнгә,*
*Елмаеп карыйм мин аңа –*
*Бәхетле билетым кулымда...*

***

*Ә мин һаман җылы өмет итәм,*
*Алай була ала, әйтерсең...*
***Р. Мөхәммәтшин***

**Гөлназ ЯППАРОВА**

*Градусникның зәһәр күрсәткече*
*Һәр көн саен түбән тәгәри.*
*Явым-төшем, буран, фәлән диләр,*
*Җылытмаска исәп әллә ни.*

*Суык тиеп чәрдәкләнгән Җиргә*
*Җиңел сулап тын алуы кыен.*
*Әллә нигә хәрәкәтсез калган*
*Зәңгәр күкнең йолдызлары быел.*

*Чәлпәрәмә коелырга тора*
*Бу дөньяның асты-өсте бүген.*
*Бу суыкның мескен Җиребезне*
*Үз итүе хәерлегә түгел.*

***

**Гөлчәчәк ХӘСНУЛЛИНА**

*Йөрәгемдә купкан давылларны,*
*Табигатьтән кара, аңларсың.*
*Җилләр уйный, якынайтам диеп,*
*Ике тиле гашыйк арасын.*

*Күпме генә җилләр тырышмасын,*
*Син еракта инде, читләштең.*
*Бүген тагын төнлә төшләремдә,*
*«Яратам» дип гүя эндәштең...*

*Ул төшемнән күзем йомылмады,*
*Еларгамы, әллә көләсе.*
*Күңелеңдә Синең ниләр икән???*
*Эх, беләсе иде, беләсе...*

*Бәлки Син дә Мине күргәнсеңдер,*
*Дәшкәнмендер төштә яратып.*
*Кайтып керсәң иде, урамдагы,*
*Күңелдәге карны таратып...*

## Унҗиденче кышым

**Ләйсән ИСХАКОВА**

*Унҗиденче кышым.Күңел тулы*
*Берәм- берәм ефәк хисләрем.*
*Тик күзнең ямансу карашы*
*Һаман да хәтердә, истә әле.*

*Кыш йолдыз чүпләргә дәшкәндә,*
*Син миңа җәйләрне юрама.*
*Күптәннән кышларга гашыйк мин,*
*Кыш моңы күңелгә урала.*

*Ябалак карларның сурәтен*
*Кадерләп сеңдерәм җанына.*
*Тырыштым. Төшендем. Аңладым –*
*Бүгеннән мин язны сагынам.*



● Тормыш әлифбасы

# КФУда уку – зур бәхет

**Альбина НУРИЕВА,** Н.И.Лобачевский исемендәге лицейның 11L сыйныф укучысы

Инде кышның икенче ае да ахырына якынлаша, аннары яз житәр, аннан соң җәй... Анда инде имтиханнарны тапшыру, мәктәп белән саубуллашу, югары уку йортлары ишекләрен ачу һәм студент дигән дәрәҗәгә ия булу! Бу барлык 11 сыйныф укучыларының якын киләчәккә корган планнары. Без хәзер белгечлек һәм уку йорты сайлау белән мәшгуль. Бу бит киләчәк тормышыңа нигез салу дигән сүз. Сер түгел, дусларымның күбесе Казан федераль университетына укырга керергә уйлый. Шул уңайдан мин берничә чыгарылыш сыйныф укучысыннан аларның ни өчен нәкъ шушы вузны сайлауларын сораштым. Җаваплар төрле һәм үзенчәлекле булды.

***Аделина Хәсәншина, Н.И.Лобачевский исемендәге лицей, 11L сыйныф:***

- Күпчелек сыйныфташларым кебек үк, мин дә КФУга укырга керергә хыялланам. Россиянең башка зур шәһәрләренә китәргә теләүчеләр дә аз түгел. Ә мин үз шәһәремдә калам, миңа монда рәхәт. Монда минем әти-әнием, туганнарым, дусларым. Казанда менә дигән укытучылар эшли һәм мәгариф системасы да югары дәрәҗәдә. Казан федераль университетында күп санда институтлар бар, сайлау спектры да бик киң. Монда, һичшиксез, күңелгә ошаган профессия алып, югары дәрәҗәле белгеч булу өчен мөмкинлекләр җитәрлек. Иң мөһиме: куркып калмаска кирәк! Чыгарылыш сыйныф укучылары алдында бик күп ишекләр «пәйда була». Бу очракта иң авыры – үзеңнең ишегеңне



Юлия Карпова фотосы

табу. Без үзебезнең мөстәкыйльлегебезне тоя белергә өйрәнергә тиеш. Бер яктан караганда, без аптыраашта: нишләргә, кая барырыга? Икенче яктан, үзеңне бу зур һәм буталчык дөньяда бик күп үрләр яуларга сәләтле, формалашып өлгергән шәхес буларак хис итү бик рәхәт.

***Михаил Абызов, Н.И.Лобачевский исемендәге лицей, 11C сыйныф:***

- Дөресен генә әйткәндә, Казан шәһәреннән читкә китәсе килми. Мәскәү, Санкт-Петербург – минем өчен бөтенләй чит шәһәрләр. Анда түләүсез бүлеккә укырга керергә дә бик кыен! Чит ил турында әйтмим дә инде. Әлегә бу якты хыялда гына. Казан федераль университетына килгәндә, ул республикабыз уку йортлары арасында иң танылганы, иң ышанычлысы һәм иң күренекле уку йортларыннан санала!

***Лилия Исмагилова, 159 лицей, 11 сыйныф:***

- КФУда белем бирү дәрәҗәсе иң яхшыдан санала. Казан шәһәренең, республиканың иң яхшы университеты!

***Владислав Матюнин, Н.И.Лобачевский исемендәге лицей, 11 F:***

- Ни өчен КФУ? Чөнки безнең Казанда аннан да престижлырак һәм яхшырак уку йорты бүтән юк!

***Екатерина Фишман, 9 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе, 11 сыйныф:***

- Әйе, мин Казан федераль университетына укырга керергә җыенам һәм шул юнәлештә җиң сызганып эшлим. Биредәге Геология һәм кара алтын-газ технологияләре институты Россиядә иң яхшылардан санала икән. Минем дә шул институт студенты дигән горур исемне йөртәсем килә.

***Айдар Шәрипов, Н.И.Лобачевский исемендәге лицей, 11F сыйныф:***

- КФУ – безнең колачлап бетергесез илебезнең иң яхшы уку йортларының берсе. Ул бер урында гына таптанып тормый, гел яхшы якка үзгәреп тора. Анда иң популяр һәм сорау зур булган юнәлешләр буенча яхшы белгечләр әзерләнә. Шулай ук Казан федераль университетының материаль базасы бик нык: студентлар әзерләгән һәм эшкәрткән күп кенә проектлар хуплана һәм финанслана. Мин студент булган дусларымнан бу уку йортында уздырылган төрле күңел ачу программалары, конференцияләр һәм спорт чаралары турында ишетеп белеп торам һәм үземне дә шушы күпкырлы студент дөньясының бер өлеше итеп тоясым килә.

DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 500
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Динара Равил кызы Миннекаева
Иҗат коллективы: А.Ю.Садыйкова
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Куранты» ЖЧЖ типографиясендә басылды, Казан ш., Журналистлар ур., 1, 317 оф.